ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2014 Казан ш. № 10-42/кс

***2015-2017 елларга эчә торган суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм субүлү турында” 2011 елның 7 декабрь № 416-ФЗ” Федераль законына, “Су белән тәэмин итү һәм субүлү өлкәсендә тарифларны дәүләт көйләве турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 май карарына, “2015 елга су белән тәэмин итү һәм субүлү өлкәсендә гамәлдәге тарифларның иң югары күләмдә мөмкин булган үзгәрешен Россия Федерациясе субьектлары буенча уртача соңгы чиктә көйләүне билгеләү турында” тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2014 елның 11 октябрь № 228-э/4 боерыгына, Татарстан республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Нигезләмәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән һәм субүлүне тәэмин итүче оешмаларга, эчә торган суга һәм субүлүгә тарифларны, шушы карарның кушымтасы белән килештереп, календарга бүлеп билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар, 2015 елның 1 гыйнвареннан 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Салкын су белән һәм субүлүне тәэмин итүче оешмаларга, 2015 – 2017 елларга эчә торган суга һәм субүлүгә тарифларны көйләүнең озак вакытка исәпләнгән күләмнәрен, шушы карарның 2 кушымтасы белән килештереп билгеләргә.

4. Шушы карарга кушымтада күрсәтелгән салкын су белән һәм субүлүне тәэмин итүче оешмаларга, су белән тәэмин итү өлкәсендә мәгълүматны җиткерүдә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнвар № 6 карары белән расланган стандартлар нигезендә, алдагы көйләү вакытына кадәр тарифларны билгеләү турында карар кабул иткәнче, 30 календар көннән дә соңга калмыйча, мәгъдүматны җиткерергә.

5. Шушы карар рәсми басылгач, ун көннән соң  үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитетының
05.12.2014 № 10 -42 /кс
карарына 1 кушымта

# Салкын су белән һәм субүлүне тәэмин итүче оешмаларга, 2015-2017 елларга календарга бүлеп, эчә торган суга һәм субүлүгә тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлек, салкын су һәм (яки) субүлүне тәэмин итүче оешмалар исемнәре | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум./куб.м | | | | | | Субүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 ел | | 2016 ел | | 2017 ел | | 2015 ел | | 2016 ел | | 2017 ел | |
| | | 01.01.2015 30.06.2015 кадәр | 01.07.2015 31.12.2015 кадәр | 01.01.2016 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 31.12.2016 кадәр | 01.01.2017 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 31.12.2017 кадәр | 01.01.2015 30.06.2015 кадәр | 01.07.2015 31.12.2015 кадәр | 01.01.2016 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 31.12.2016 кадәр | 01.01.2017 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 31.12.2017 кадәр |
| | Арча муниципаль районы | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Водоканал-Сервис» ҖЧҖ | 33,32 | 34,80 | 34,80 | 37,19 | 37,19 | 38,69 | 38,00 | 38,72 | 38,72 | 42,10 | 42,10 | 42,59 |
| 2 | «Новокинерское МПП ЖКХ»ААҖ | | | | | | | | | | | | |
| 2.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпләп күрсәтелгән)* | 32,08 | 33,97 | 33,97 | 35,59 | 35,59 | 37,48 | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 27,19 | 28,79 | 28,79 | 30,16 | 30,16 | 31,76 | | | | | | |

<*>Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддасе 6 пунктын үтәү максатларында аерып күрсәтелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контроль һәм җиткерү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитетының
05.12.2014 № 10 -42 /кс
карарына 2 кушымта

## Салкын су белән һәм субүлүне тәэмин итүче оешмаларга, 2015 – 2017 елларга эчә торган суга һәм субүлүгә тарифларны көйләүнең озак вакытка исәпләнгән күләмнәре

| № т/б | Салкын су һәм (яки) субүлүне тәэмин итүче оешмалар исемнәре, тариф төрләре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норма дәрәҗәсе | Энергия саклау һәм энергетик нәтиҗәлелек күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Суны югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең. сум. | % | % | % | кВт·с/м.куб. |
| 1 | «Водоканал-Сервис» ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган суга тарифлар | 2015 | 12023,21 | 1 | 0 | 4,4 | 2,18 |
| | | 2016 | 12507,31 | 1 | 0 | 4,4 | 2,18 |
| | | 2017 | 12992,75 | 1 | 0 | 4,4 | 2,18 |
| 1.2 | Субүлүгә тарифлар | 2015 | 8476,05 | 1 | 0 | - | 2,05 |
| | | 2016 | 8791,76 | 1 | 0 | - | 2,05 |
| | | 2017 | 8793,38 | 1 | 0 | - | 2,05 |
| 2 | «Новокинерское МПП ЖКХ» ААҖ | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1 | Эчә торга суга тарифлар | 2015 | 771,61 | 1 | 0 | 1,2 | 1,42 |
| | | 2016 | 802,53 | 1 | 0 | 1,2 | 1,42 |
| | | 2017 | 833,39 | 1 | 0 | 1,2 | 1,42 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контроль һәм җиткерү бүлеге